КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 ел, 24 март

г.Казань

№ 267

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 ноябрь, 1005 нче; 2020 ел, 24 ноябрь, 1057 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1118 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясы, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы, «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Террито-

рияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның $13^1$ статьясындагы 2 өлешендә каралган чараларны финанслау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин